| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30.06.2014 Казан ш. №311-пр

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында**

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурслар үткәрүнең нәтиҗәлелеген тәэмин итү максатыннан чыгып, боерык бирәм:

1. Расларга (кушымта итеп бирелә):

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләү буенча Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының конкурс комиссиясе турында нигезләмәне;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләти

гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү методикасын.

2.Министрлыкның кадрлар секторына йөкләргә:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләү буенча Министрлыкның конкурс комиссиясе эшен тәэмин итү;

“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның һәм дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтларында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү һәм аның нәтиҗәләре турында мәгълүматны урнаштыру.

3. Финанс һәм дәүләт заказы бүлегенә Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурслар үткәрү белән бәйле чыгымнарны финанслауны, шул исәптән бәйсез экспертлар хезмәтенә түләү чыгымнарын Министрлык аппаратын тотуга күздә тотылган Татарстан Республикасы бюджет средстволары чикләрендә тәэмин итәргә.

4. Үз көчен югалткан дип танырга:

“Дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләү буенча Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының конкурс комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында” 30.12.2006 ел, №469 Министрлык боерыгын;

“Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын

биләүгә конкурс үткәрү методикасын раслау турында” 30.12.2006, №470 Министрлык боерыгын;

“Дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләү буенча Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының конкурс комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында” 30.12.2006, №469 боерыкка үзгәрешләр кертү турында” 09.06.2009, №213 Министрлык боерыгын;

“Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү методикасына үзгәрешләр кертү турында” 20.07.2009, №297 Министрлык боерыгын;

“Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 30.12.2006, №470 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү методикасына үзгәрешләр кертү турында” 14.03.2011, №78 Министрлык боерыгын;

“Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 30.12.2006, №470 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү методикасының 6 пунктына үзгәреш кертү турында” 17.05.2011, №188-пр Министрлык боерыгын;

“Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 30.12.2006, №469 боерыгы белән расланган дәүләти

гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләү буенча Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының конкурс комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында” 09.08.2013, №397-пр Министрлык боерыгын.

5. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Министр** **А.К.Хамаев**

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының
30.06.2014 ел, № 311-пр
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләү буенча Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының конкурс комиссиясе турында нигезләмә**

1. Бу Нигезләмә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс (алга таба – Конкурс) үткәрелгәндә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләү буенча Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының конкурс комиссиясе (алга таба – Конкурс комиссиясе) составын, эшчәнлеге срокларын һәм тәртибен билгели.

2. Министрлыкның конкурс комиссиясе Конкурс комиссиясе рәисеннән, рәисе урынбасары, секретаре һәм әгъзаларыннан тора.

Конкурс комиссиясенең персональ составы Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры (алга таба – Министр) боерыгы белән раслана.

3. Конкурс комиссиясе составына Министр һәм аның тарафыннан вәкаләт бирелгән гражданлык хезмәткәрләре, шул исәптән Министрлыкның кадрлар секторыннан, хокук идарәсеннән һәм Конкурс үткәрелә торган

подразделениедән), Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан Министр запросы буенча Татарстан Республикасы Дәүләти гражданлык хезмәтенә бәйле мәсьәләләр буенча бәйсез экспертлар, белгечләр сыйфатында чакырыла торган фәнни, мәгариф оешмалар һәм башка оешмалар вәкилләре, экспертларның персональ мәгълүматларын күрсәтмичә, керә. Бәйсез экспертлар саны Конкурс комиссиясе саны әгъзаларының гомуми саныннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

Конкурс комиссиясе составына, бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән затлар белән беррәттән, Министрлыкта оештырылган иҗтимагый совет вәкилләре кертелә.

Әлеге вәкилләрнең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны Конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан кимендә дүрттән бер өлешне тәшкил итәргә тиеш.

Конкурс комиссиясе составына кертү өчен Министрлык каршындагы иҗтимагый совет вәкилләре кандидатуралары Министр запросы буенча әлеге совет тарафыннан тәкъдим ителә.

4. Дәүләт сере булып торган мәгълүматлардан файдалануга бәйле вазыйфаи бурычларны үтәү буенча Конкурс үткәрү өчен Конкурс комиссиясе составы дәүләт сере турында Россия Федерациясе законы нигезләмәләреннән чыгып булдырыла.

5. Конкурс комиссиясе составы Конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясардай мәнфәгатьләр бәрелеше ихтималын булдырмаслык итеп формалаштырыла.

6. Конкурс комиссиясе рәисе Конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм аның эшен оештыра, утырыш үткәрү датасын билгели һәм аның көн тәртибен раслый, Конкурс комиссиясе утырышларында рәислек итә, Конкурс комиссиясе эшчәнлегенә бәйле башка вазыйфалар башкара.

Конкурс комиссиясе рәисе югында аның хокукларын һәм бурычларын Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары үти.

7. Конкурс комиссиясе секретаре Конкурс комиссиясе эшен тәэмин итә:

Конкурс комиссиясе утырышының көн тәртибе проектын төзи, Конкурс комиссиясе утырышларына материаллар әзерләүне оештыра;

чираттагы утырышны уздыру турында Конкурс комиссиясе әгъзаларына хәбәр итә;

Конкурс комиссиясе әгъзаларына Конкурс комиссиясе утырышын үткәрү датасы, урыны, вакыты турында мәгълүмат җиткерә, аларны кирәкле материаллар белән тәэмин итә;

гаризалар, документларны кабул итә һәм терки;

Конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә;

карарлар проектларын әзерли;

делопроизводствоны алып бара;

рәисе кушуы буенча Конкурс комиссиясе эшенә бәйле башка төрле гамәлләр башкара.

Конкурс комиссиясе секретаре Конкурс комиссиясе утырышын оештыра һәм аның әгъзаларына утырышны үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында кимендә җиде көн кала җиткерә.

8. Конкурс комиссиясе утырышларында беркетмә тутырыла, беркетмәдә кабул ителгән карарлар, Конкурс җиңүчесен билгеләү буенча тавыш бирү

нәтиҗәләре теркәлә. Конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә Конкурс комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, әгъзалары һәм Конкурс комиссиясе секретаре кул куя.

9. Конкурс комиссиясе утырышы Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең (алга таба – гражданлык хезмәте) вакантлы вазыйфасын биләүгә кимендә ике кандидат булганда үткәрелә.

Конкурс комиссиясе утырышында аның әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән ике өлеше катнашкан очракта, утырыш узды, дип санала. Конкурс комиссиясе утырышын дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалары катнашында гына үткәрү рөхсәт ителми.

Конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча Конкурс комиссиясе карары утырышта катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән, ачык тавыш юлы нигезендә кабул ителә. Тавышлар бертигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

10. Конкурс комиссиясе утырышы датасы Конкурс үткәрү турында карар кабул ителгәннән соң билгеләнә.

11. Конкурс комиссиясе беренче этапта Конкурс үткәрү тәртибен, шул исәптән конкурс процедураларын билгели, аларга кандидатлар дәгъва кыла торган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү белән бәйле рәвештә индивидуаль әңгәмә, анкета, төркемләп дискуссияләр уздыру, реферат яздыру яки тест үткәрү кертелергә мөмкин.

12. Конкурс комиссиясе икенче этапта Конкурс уздыра, ул кандидатларның Министрлыкта гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә, шулай ук кадрлар резервын булдыру максатыннан чыгып, һөнәри

дәрәҗәсен, аларның гражданлык хезмәте вазыйфасына карата Министрлыкта билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

Конкурс үткәргәндә Конкурс комиссиясе белеме, гражданлык хезмәте яки башка төрле дәүләт хезмәте үтү, башка хезмәт эшчәнлеген башкару турында кандидатлар тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә, шулай ук билгеләнгән конкурс процедуралары нигезендә кандидатларны бәяли.

Конкурс комиссиясе кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатын бәялəгәндә, Конкурс үткәрелә торган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына карата тиешле квалификация таләпләреннән чыгып, Министрлыкта бу вазыйфа буенча вазыйфаи регламент, шулай ук дәүләти гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән нигезләмәләрдән чыгып эш итә.

13. Конкурс комиссиясе карары кандидат югында кабул ителә һәм аны гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билəүгә яки мондый биләүдән баш тартуга нигез булып тора.

Конкурс комиссиясе гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста җиңмәгән, әмма һөнәри һәм шәхсән сыйфатлары югары бәяләнгән кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында тәкъдим итү характерында карар кабул итүгә хокуклы.

14. Конкурс комиссиясе хокуклы:

Конкурс комиссиясе эше өчен кирәкле булган мәгълүматлар һәм материалларны министрлыкның структур подразделениеләре җитәкчеләреннән соратып алуга;

Конкурста җиңүчене вакантлы вазыйфага билгеләгәндә һәм аның белән хезмәт контрактын төзегәндә сынау срогы һәм аның дәвамлылыгын билгеләү буенча тәкъдимнәр бирүгә;

Конкурста җиңгән кандидат вакантлы вазыйфага хезмәт контракты төзүдән баш тарткан очракта, үзен хуплап иң күп тавыш бирелгән икенче кандидатны вакантлы вазыйфага биләүгә тәкъдим итүгә;

Конкурста җиңмәгән, әмма һөнәри һәм шәхсән сыйфатлары ягыннан югары бәяләнгән кандидатны Министрлыкны кадрлар резервына кертү турында тәкъдимнәр бирүгә.

15. Конкурс комиссиясе эшчәнлеген оештыру, техник яктан тәэмин итүне Министрлыкның кадрлар секторы хәл итә.

16. Гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә кандидат Конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законы нигезендә шикаять белдерүгә хокуклы.

Татарстан Республикасы Җир һәм
мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының
30.06.2014 ел, № 311-пр боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү методикасы**

1.Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс (алга таба – Конкурс) Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләүдән һәм Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте (алга таба – гражданлык хезмәте) вазыйфасына карата билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт булып, ике этапта уздырыла.

2. Конкурс, Конкурс буенча билгеләнелә торган вакантлы вазыйфага ия булган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (алга таба – Министрлык) структур подразделениесе начальнигының яисә Министрлыкның кадрлар секторы мөдиренең нигезле язмача мөрәҗәгате буенча, Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры боерыгы белән игълан ителә.

Язмача нигезеле мөрәҗәгатьләрдә Конкурс игълан итү турында үтенечтән тыш, гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы атамасы, шулай ук кандидатны вакантлы вазыйфага биләүгә тест үткәрү өчен кирәкле теоретик сораулар һәм тормыштан алынган конкрет бурычлар исемлеге урын алырга тиеш.

3.Конкурс үткәрелми:

гражданлык хезмәтенең кече вазыйфалар төркеменә керүче гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

вакытлы хезмәт контракты төзегәндә;

“җитәкчеләр” һәм “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категорияләрендә гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеле бер вәкаләтләр срогына билгеләгәндә;

Дәүләти гражданлык хезмәткәрен (алга таба – Гражданлык хезмәткәре) “Россия Федерациясендә дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, №79-ФЗ Федераль законның 28 статьясындагы 2 өлешендә, 31 статьясындагы 1 өлешендә, 60.1 статьясындагы 9 өлешендә күздә тотылган очракларда, башка гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә;

Министрлыкта гражданлык хезмәтенең кадрлар резервына кертелгән Гражданлык хезмәткәрен (гражданин) гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

4. Вазыйфаи бурычларын үтәү Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры (алга таба – Министр) боерыгы белән расланыла торган вазыйфалар исемлеге буенча дәүләт сере булып торучы мәгълүматлардан файдалануга бәйле булган гражданлык хезмәтенең аерым вазыйфаларына билгеләгәндә, Министрлыкта конкурс үткәрелмәскә мөмкин.

5. Унсигез яшькә җитеп, Россия Федерациясе дәүләт телен белүче һәм дәүләти гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына карата квалификация таләпләренә туры килүче Россия Федерациясе гражданнары конкурста катнашуга хокуклы.

Гражданлык хезмәткәре, Конкурс үткәрү чорында нинди вазыйфа биләвенә карамастан, Конкурста гомуми нигезләрдә катнашуга хокуклы.

6. Конкурс ике этапта уздырыла. Беренче этабында “Интернет-мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның һәм дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтларында Конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында белдерү, шулай ук Конкурс үткәрү турында түбәндәге мәгълүмат: гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы атамасы; әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучыга карата куела торган таләпләр; гражданлык хезмәтен үтү шартлары; бу Методиканың 7-9 пунктлары нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабу итү урыны һәм вакыты; әлеге документларны кабул итү срогы; конкурс үткәрүнең күздә тотылган датасы; аны үткәрү урыны һәм тәртибе; башка мәгълүмати материаллар урнаштырыла.

7. Конкурста катнашуга теләк белдергән гражданин Министрның Кадрлар секторына (алга таба – Кадрлар секторы) тапшыра:

үзе дәгъва кыла торган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы атамасын, шулай ук яшәү урынын (вакытлыча булу урыны), элемтәгә керү өчен телефоннарын күрсәтеп, Конкурста катнашуга кертүгә шәхсән гариза;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 26 май, 2005 ел, №667-р боерыгы белән расланган форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имза салган анкета;

паспорт яки аны алыштыручы документ (хәрби билет, шәхесне раслаучы документ) күчермәсе;

кирәкле һөнәри белемен, квалификациясен һәм эш стажын раслаучы докментлар;

хезмәт кенәгәсе күчермәсе (хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлегенә тәүге тапкыр керешү очракларыннан тыш) яки гражданинның хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлеген раслаучы башка документлар күчермәсе (нотариуста яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәтендә расланган);

белеме һәм квалификациясе турында документлар күчермәләре, шулай ук гражданинның теләгенә карап – өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификациясен күтәрүне яки квалификация бирүне раслаган документлар, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турында документлар күчермәләре (нотариуста яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәтендә расланган);

4х6 см үлчәмендәге ике фотосурәт;

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 14.12.2009 ел, №984-н боерыгы белән расланган форма нигезендә, Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенә һәм муниципаль хезмәткә керүгә һәм аны үтүгә комачаулардай авырудан интегүе (интекмәве) турында медицина оешмасы белешмәсе;

запастагы  гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен – хәрби учет документлары;

Россия Федерациясе законы нигезендә, кереме, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары, шулай ук хатынының (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар (“Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында гражданнар Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләнгәндә һәм Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләре үзләренең вазыйфасын биләгәндә керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары, шулай ук

хатынының (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшыруны таләп итүче Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында" 25.01.2010 ел, №19 Министрлык боерыгында күрсәтелгән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә Конкурста катнашучы гражданнар тарафыннан тапшырыла);

Федераль законда һәм Татарстан Республикасы законында күздә тотылган башка документлар.

8. Министрлыкта конкурста катнашуга теләк белдергән Министрлыкның гражданлык хезмәткәре Министр исеменә гариза тапшыра.

Башка дәүләт органында Конкурста катнашуга теләк белдергән Министрлыкның гражданлык хезмәткәре бу дәүләт органына эшкә яллаучы вәкиле исеменә гариза һәм үз кулы белән тутырылган, имза салынган һәм Кадрлар секторы раслаган анкета (фотосурәтләре белән) тапшыра. Анкета формасы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана.

9. Башка дәүләт органында хезмәт итеп, Министрлыкта Конкурста катнашуга теләк белдергән гражданлык хезмәткәре Министр исеменә гариза һәм үз кулы белән тутырылган, имза салынган һәм Гражданлык хезмәткәре үзе дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасын били торган дәүләт органының кадрлар хезмәте раслаган анкета (фотосурәтләре белән) тапшыра.

10. Гражданин (гражданлык хезмәткәре) гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына карата квалификация таләпләренә туры килмәве сәбәпле, шулай ук дәүләти гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе законында билгеләнгән дәүләти гражданлык хезмәтенә керү һәм аны үтү өчен чикләүләргә бәйле сәбәпле Конкурста катнашуга кертелми.

Гражданин түбәндәге очракларда Конкурста катнашуга кертелми:

законлы көченә кергән суд карары нигезендә эшкә сәләтсез яки эшкә сәләтлелеге чикләнгән дип танылганда;

закон көченә кергән суд карары нигезендә дәүләт хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү мөмкинлеге бирмәгән җәзага хөкем ителгәндә, шулай ук федераль закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә хөкем җәзасы үзеннән алынмаганда яки үтәлмәгәндә;

гражданин дәгъва кыла торган дәүләт хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт сере һәм федераль закон нигезендә саклана торган сер булып торганда, яисә Гражданлык хезмәткәре били торган гражданлык хезмәте вазыйфасы мондый мәгълүматлар файдалануга бәйле булганда, мондый мәгълүматлар белән эш итүгә рөхсәт бирүне рәсмиләштерү процедурасын үтүдән баш тартканда;

гражданлык хезмәтенә керүгә яки аны үтүгә комачаулардай авырудан (медицина оешмасы белешмәсе белән расланган) интеккәндә; Гражданлык хезмәткәре белән якын туган яки якын мөнәсәбәттә булганда (ата-аналар, ир белән хатын, балалар, абый-энеләр, апа-сеңелләр, шулай ук иренең (хатыны), абый-энеләре, апа-сеңелләре, ата-аналары, балалары һәм балаларының ирләре (хатыннары), гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү берсенең икенчесенә турыдан-туры буйсынуына яки контрольлегенә бәйле булганда;

Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгу яки башка дәүләт гражданлыгын алу;

башка дәүләт (башка дәүләтләр) гражданлыгына ия булу, Россия Федерациясе халыкара килешүендә башкача күздә тотылмаганда;

гражданлык хезмәтенә кергәндә ялган документлар яки белә торып ялган мәгълүматлар тапшыру;

гражданлык хезмәтенә кергәндә керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән мәгълүматларны тапшырмау яки белә торып ялган мәгълүматлар тапшыру;

“Россия Федерациясендә дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, №79-ФЗ Федераль закон, “Коррупциягә каршы көрәш турында” 25 декабрь, 2008 ел, №273-ФЗ Федераль закон һәм башка федераль законнар нигезендә коррупциягә каршы көрәш максатында билгеләнгән бурычларны үтәмәү, мәнфәгатьләр бәрелешен кисәтү яки җайга салу турында таләпләрне, чикләүләр һәм тыюларны үтәмәү очракларда Министрның (эшкә яллаучы вәкиле) Гражданлык хезмәткәренә карата ышанычын югалтуы;

чакырылыш комиссиясе белешмәсе нигезендә законлы нигезләргә ия булмаган килеш чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтмәгән дип танылуы (контракт буенча хәрби хезмәт үткәрү гражданнардан тыш).

11. 7-9 пунктларда күрсәтелгән документлар Министрлыкка, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында документларны кабул итү турында белдерү урнаштырылганнан соң 21 көн эчендә, тапшырыла.

Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмендә тапшырмау яки нигезле сәбәпсез рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданинга документларын кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

12. Кадрлар секторы кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны кабул итеп, махсус журналда терки, аларны рәсмиләштерүнең

тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә, гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатлар тапшырган мәгълүматларның дөреслеген билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

13. Министр Кадрлар секторы тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча кандидатларны Конкурска катнашуга кертү яки Конкурста катнашуга кертүдән баш тарту турында карар кабул итә, шулай ук Конкурсның икенче этабын үткәрү датасын, урынын һәм вакытын билгели.

Кадрлар секторы Россия Федерациясе законы нигезендә гражданинның гражданлык хезмәтенә керүенә комачаулардай хәлләр билгеләгән очракта Министр тарафыннан карар кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча Конкурста катнашуга кертелмәгән кандидатларга Конкурста катнашуга кертүдән баш тарту сәбәпләре турында язмача хәбәр итә.

14. Конкурста катнашуга кертелмәгән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъвачы бу карарга Россия Федерациясе законы нигезендә шикаять белдерүгә хокуклы.

15. Кадрлар секторы Конкурсның икенче этабы башланырга кимендә 15 көн кала Конкурста катнашуга кертелгән гражданнарга (Гражаданлык хезмәткәрләргә) (алга таба – кандидатлар) аны үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында хәбәр җиткерә.

16. Конкурсның икенче этабы бер үк көнне уздырыла торган ике статьядан тора.

Министрлыкның гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләү буенча конкурс комиссиясе (алга таба – Конкурс комиссиясе) беренче стадиядә кандидатлар тарафыннан тапшырылган белем, гражданлык хезмәтен яки башка дәүләт хезмәтен үтү,

башка хезмәт эшчәнлеген хәл итү турында документлары нигезендә кандидатларны бәяли, бу Методиканың 7-9 пунктларына туры китереп, вакантлы вазыйфаны биләүгә кандидатлар тарафыннан тәкъдим ителгән документларга чагыштырма анализ ясый, кандидатларның гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасына карата билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен билгели, һәр вакантлы вазыйфа буенча Конкурс үткәрү ысулларын билгели.

17. Конкурсның икенче стадиясе, тест уздыру; төркемләп дискуссияләр үткәрү, реферат яздыру, индивидуаль әңгәмә һ.б. кертеп, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәгән кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләү ысулларын кулланып үткәрелә.

Кандидатларга Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, Федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә, хокукларының бертигез булуы гарантияләнә.

Югарыда санап үтелгән барлык ысулларны да куллану мәҗбүри түгел.

Шул ысулларның берсе (мәсәлән, тест) нигезендә вакантлы вазыйфага Конкурста җиңүче ачыкланган очракта, Конкурс төгәлләнгән булып санала.

18. Кандидатлар арасында конкрет вакантлы вазыйфага тест үткәрү вакантлы вазыйфага ия булган структур подразделение тарафыннан алдан әзерләп куелган бердәм теоретик сораулар исемлеге буенча хәл ителә. Тест Министр тарафыннан расланган Министрлыкның Гражданлык хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәү өчен кирәкле һөнәри белемнәр һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләре базасында төзелә.

Вакантлы вазыйфага кандидатларга тест буенча язмача җавап әзерләү өчен бер үк вакыт бирелә.

Тестны бәяләү дөрес җаваплар саны буенча хәл ителә. Тестларда хаталы җаваплар саны 25 проценттан артыграк булмаска тиеш. Тест кимендә 10 һәм күп дигәндә 30 сораудан торырга тиеш.

19. Дискуссияләрне үткәрү вакантлы вазыйфага ия булган структур подразделение тарафыннан алдан ук әзерләп куелган сорауларга конкрет очракларга нигезләнеп хәл ителә.

Вакантлы вазыйфага кандидатлар бер үк биремнәр ала һәм аларга телдән җавап әзерләү өчен бер үк вакыт бирелә.

Конкурс комиссиясе, телдән җавап нәтиҗәләреннән һәм дискуссиядә катнашудан чыгып вакантлы вазыйфага кандидатны бәяли һәм сайлап ала.

20. Реферат язу өчен кандидатлар дәгъва кыла торган гражданлык хезмәте вазыйфасы буенча  вазыйфаи бурычларны һәм вәкаләтләрне үтәүгә бәйле сораулар кулланыла. Рефератлар темасын вакантлы вазыйфага ия булган структур подразделение билгели.

Вакантлы вазыйфага кандидатлар бер үк темага реферат яза һәм аларга аны әзерләү өчен бер үк вакыт бирелә. Кандидатлар тарафыннан рефератлар әзерләү Конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнгән бүлмәдә, Конкурс комиссиясе әгъзаларының күз алдында хәл ителә.

Рефератлар кандидатлар тарафыннан Конкурс комиссиясенә язмача рәвештә тапшырыла.

Конкурс комиссиясе рефератларына материалны бәян итү сыйфаты һәм тирәнлеге, сорауны  мәсьәләне ачуның тулылыгы буенча бәяли.

21. Кандидатларны бәяләү максатыннан чыгып, Конкурс комиссиясе әгъзалары, №1 кушымта нигезендә, гражданлык хезмәтенең вакантлы

вазыйфасын биләүгә һәр кандидат буенча Министрлыкның Конкурс комиссиясе әгъзасының тавыш бирү кәгазен тутыра.

Тавыш бирү кәгазендәге мәгълүматлар, № 2 кушымта нигезендә, Конкурс комиссиясе әгъзаларының тавыш бирү йомгаклары буенча рәсмиләштерелә торган Конкурс бюллетененә кертелә.

22. Конкурс комиссиясе, Конкурста катнашучы барча кешене бәяләп, алар туплаган тавышларны исәпләгәннән соң Конкурс җиңүчесен билгели. “Әйе” тавышын иң күп җыйган кандидат Конкурста җиңгән дип санала.

Тавышлар бертигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

23. Конкурс нәтиҗәләре Конкурс комиссиясе беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, аңа конкурсны үткәрү көнендә Комиссия рәисе, Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары, секретаре һәм әгъзалары имза сала.

Кадрлар секторы Конкурс нәтиҗәләре турында хәбәрне конкурс тәмамланганнан соң җиде көн эчендә кандидатларга язмача җибәрә.

Шулай ук конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат күрсәтелгән срокта “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның һәм дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтларында урнаштырыла.

24. Конкурста катнашкан кандидатларның берсен җиңүче дип тану турында Конкурс комиссиясе карары нигезендә, Конкурста җиңүчене гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү турында Министр боерыгы басылып чыга һәм Конкурс җиңүчесе белән хезмәт контракты төзелә.

25. Конкурс комиссиясе тарафыннан Конкурста җиңмәгән кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында карар кабул ителгән

очракта, әлеге зат ризалыгы белән, гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы нинди төркемгә керсә, шул төркемдәге гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында Министр боерыгы басылып чыга.

26. Конкурста катнашуга кертелмәгән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучыларның һәм Конкурста катнашкан кандидатларның документлары Конкурс тәмамланганнан соң өч ел эчендә язмача гариза нигезендә кире кайтарып бирелә. Бу срок чыкканнан соң документлар Министрлык архивында саклана, шуннан соң юкка чыгарыла.

27. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар Конкурс үткәрү урынына барып кайту, торак наемы, яшәү, элемтә чаралары хезмәтеннән файдалану һ.б. чыгымнары) кандидатлар тарафыннан үз средстволары хисабына хәл ителә.

28. Гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә кандидат Конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законы нигезендә шикаять белдерүгә хокуклы.

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү методикасына № 1 кушымта

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы Конкурс комиссиясе әгъзасының тавыш бирү**

**КӘГАЗЕ**

| № п/п | Кандидатның Ф.И.О. | Тавыш бирү нәтиҗәләре | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| | | Әйе яки Юк | |
| 1 | | | |
| 2 | | | |
| 3 | | | |

Конкурс комиссиясе әгъзасы __________ ______________

(имза) (тулы имза)

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү методикасына № 2 кушымта

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы Конкурс комиссиясе әгъзасының тавыш бирү конкурс бюллетене**

__________________________________________________________________

(Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы атамасы)

| № п/п | Конкурс комиссиясе әгъзасының ФИО | Тавыш бирү нәтиҗәләре | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | (Кандидатның ФИО) | | (Кандидатның ФИО) | |
| | | Әйе | Юк | Әйе | Юк |
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |
| 3 | | | | | |
| Барлык тавышлар | | | | | |

Конкурс комиссиясе рәисе __________________
(имза)

Конкурс комиссиясе секретаре ____________
(имза)